**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.08.2013 № 10-27/кс

Казан ш.

***«Торак хуҗалыгының һәм төзекләндерүнең күптармаклы җитештерү берләшмәсе» ЯАЖ күрсәтә торган каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү хезмәтләре тарифын вакытыннан алда яңадан карау турында***

«Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында» 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ номерлы федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә бәя куюю нигезләре һәм тарифларны, өстәмәләрне һәм чик дәрәҗә индексларын җайга салу тәртибе турында» 2008 елның 14 июлендәге 520 номерлы Карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карар бирә:

1. Кушымтага туры китереп, «Торак хуҗалыгының һәм төзекләндерүнең күптармаклы җитештерү берләшмәсе» ЯАЖ күрсәтә торган каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү хезмәтләре тарифын вакытыннан алда яңадан карау һәм билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2013 елның 1 сентябреннән 2013 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә булачак.

3. 2 нче кушымта нигезендә  әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән тарифның гамәлдә булу чорына каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү хезмәтләрен күрсәтә торган «Торак хуҗалыгының һәм төзекләндерүнең күптармаклы җитештерү берләшмәсе» ЯАЖ җитештерү программасының төп күрсәткечләрен килештерергә.

3. «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү буенча күптармаклы җитештерү берләшмәсе» ЯАЖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 30 декабрендәге 1140 номерлы карары белән расланган мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

5. «Коммуналь комплекс оешмалары товарларына һәм хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында» 2012 елның 30 ноябрендәге 10-34/жкх номерлы

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карарына 1 нче кушымтаның 4 пунктын һәм 4 нче кушымтаның 3 пунктын үз көчләрен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
02.08.2013 № 10-27/кс
карарына кушымта № 1

«Торак хуҗалыгының һәм төзекләндерүнең күптармаклы җитештерү берләшмәсе» ЯАҖ күрсәтә торган каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү хезмәтләренә тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, коммуналь комплекс оешмасының аталышы | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү тарифлары, сум/куб м. |
|---|---|---|
| | Алабуга муниципаль районы | |
| 1 | «Торак хуҗалыгының һәм төзекләндерүнең күптармаклы җитештерү берләшмәсе» ЯАҖ (өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча) | 75,60 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
02.08.2013 № 10-27/кс
карарына кушымта № 1

## Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү хезмәтләре күрсәтә торган «Торак хуҗалыгының һәм төзекләндерүнең күптармаклы җитештерү берләшмәсе» ЯАЖ җитештерү программасының төп күрсәткечләре

| № п/п | Коммуналь комплекс оешмасының аталышы | Коммуналь комплекс оешмасының җитештерү программасы күрсәткечләре, мең куб. м | | | | Кирәкле тулай табыш, мең сум (өстәмә хак салымыннан башка) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күму күләме, шул исәптән: | | | | |
| | | Барлыгы | Халык | Бюджет кулланучылары | Башка төр кулланучылар | |
| 1 | «Торак хуҗалыгының һәм төзекләндерүнең күптармаклы җитештерү берләшмәсе» ЯАЖ (өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча) | 53,978 | 0 | 0,027 | 53,951 | 4080,96 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм